**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

17.08.2016 № 770 - п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» № 273-ФЗ Федераль законны, 2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» № 79-ФЗ Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 21 июлендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында” № 925 указын, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасы гражданлык хезмәтенең аларга билгеләнгәндә гражданнар һәм аларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында» № ПУ-701 указын үтәү максатында,

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында

аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә Вазифалар исемлегенә кертелгән вазифаларны биләгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә, алар эштән куылганда, 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясында каралган чикләмәләре, бурычлары һәм җаваплылыклары турында аңлатырга.

3. Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлегенә (Г.Р. Хәннанова) боерыкны Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Исемлеккә кертелгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә (Ш.К. Сәлимгәрәев) боерыкның күчермәсен, ул Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенәөч көнлек чорда җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2015 елның 24 февралендәге «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында»гы № 133-п, 2015 елның 4 июлендәге «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2015 елның 24 февралендәге «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында»гы № 133-п боерыгына үзгәрешләр кертү хакында»гы № 472-п боерыкларын көчен югалткан дип танырга.

6. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый ресурслар
министрлыгының 2016 елның
«17» августында № 770-п
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгында аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә гражданнар үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары исемлеге**

**Дәүләт гражданлык хезмәтенең иң югары вазифалар төркеме:**
министрның беренче урынбасары,
министр урынбасары.

**Дәүләт гражданлык хезмәтенең төп вазифалар төркеме:**
эшләр белән идарә итүче,
Икътисад һәм инвестиция эшчәнлеге идарәсе башлыгы,
Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу идарәсе башлыгы,
Әйләнә-тирәлекне саклау идарәсе башлыгы,
Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе башлыгы,
Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгы,
финанс контрольлеге, исәпкә алу һәм хисапнамә бүлеге башлыгы,
хокукый тәэминат бүлеге башлыгы,
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы,
территориаль идарә башлыгы.

**Дәүләт гражданлык хезмәтенең әйдәп баручы вазифалар төркеме:**
министр ярдәмчесе,
финанс контрольлеге, исәпкә алу һәм хисапнамә бүлеге башлыгы урынбасары,
дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы,
әйләнә-тирәлекне саклау икътисады бүлеге башлыгы,
инвестиция программаларын үтәү бүлеге башлыгы,
дәүләт заказы, конкурс торглары бүлеге башлыгы,
дәүләт экология экспертизасы бүлеге башлыгы,

әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу бүлеге башлыгы,
атмосфера һавасын саклау бүлеге башлыгы,
су объектларын саклау бүлеге башлыгы,
җир ресурсларын саклау бүлеге башлыгы,
углеводород чималы геологиясе бүлеге башлыгы,
каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы,
гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге башлыгы,
җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге башлыгы,
мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик тирәлекне мониторинглау бүлеге башлыгы,
җир асты байлыкларыннан файдалануны үстерү бүлеге башлыгы,
административ бүлек башлыгы,
территориаль идарә башлыгы урынбасары,
территориаль идарә консультанты,
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе башлыгы урынбасары,
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе консультанты.

**Дәүләт граждanлык хезмәтенең өлкән вазифалар төркеме:**
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 2 разрядлы өлкән белгече,
Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясенең 3 разрядлы өлкән белгече,
территориаль идарәнең 2 разрядлы өлкән белгече,
территориаль идарәнең 3 разрядлы өлкән белгече.

**Дәүләт гражданлык хезмәтенең кече вазифалар төркеме:**
территориаль идарәнең 1 разрядлы белгече.